# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об образовании»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 февраля 2025 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 3 (часть I), № 40 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 54 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 26 (часть I), № 57 (часть I); 2021, № 36 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 24 (часть I), № 49 (часть I), № 77 (часть I), № 90 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 11 (часть I), № 27 (часть I), № 73 (часть I), № 92 (часть I); 2024, № 28 (часть I), № 45 (часть I) следующие изменения:

1) в части 3 статьи 4 слова «перечню документации, подготовка которой осуществляется педагогическими работниками при реализации основных общеобразовательных программ, вправе утвердить дополнительный перечень такой документации» заменить словами «перечню документов, указанному в пункте 1 части $6^1$ статьи 47 Федерального закона, вправе утвердить дополнительный перечень документов, подготовка которых осуществляется педагогическими работниками при реализации основных общеобразовательных программ»;

2) в статье 15:

а) наименование дополнить словами «, инвалидами (детьми-инвалидами)»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Условия организации обучения и воспитания обучающихся с ограниченными возможностями здоровья, инвалидов (детей-инвалидов) определяются в рекомендациях психолого-медико-педагогической комиссии, а для инвалидов (детей-инвалидов) также в соответствии с индивидуальной программой реабилитации и абилитации инвалида (ребенка-инвалида).»;

в) в части 2 первое предложение изложить в следующей редакции: «Общее образование обучающихся с ограниченными возможностями здоровья, инвалидов (детей-инвалидов) осуществляется в организациях, осуществляющих образовательную деятельность по адаптированным основным общеобразовательным программам, в соответствии с рекомендациями психолого-медико-педагогической комиссии.»;

г) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Под специальными условиями для получения образования обучающимися с ограниченными возможностями здоровья, инвалидами (детьми-инвалидами) в настоящем Законе понимаются:

1) условия обучения, воспитания и развития, обеспечивающие адаптацию содержания образования и включающие в себя использование адаптированных образовательных программ, методов и средств обучения и воспитания, учитывающих особенности психофизического развития таких обучающихся и состояние их здоровья;

2) проведение групповых и индивидуальных коррекционных занятий;

3) обеспечение специальными учебниками, учебными пособиями и дидактическими материалами, специальными техническими средствами обучения коллективного и индивидуального пользования;

4) обеспечение предоставления услуг ассистента (помощника), оказывающего необходимую техническую помощь, переводчика русского жестового языка (сурдопереводчика, тифлосурдопереводчика), а также педагогических работников в соответствии с рекомендациями психолого-медико-педагогической комиссии;

5) обеспечение доступа в здания и помещения организаций, осуществляющих образовательную деятельность;

6) другие условия, без которых освоение образовательных программ обучающимися с ограниченными возможностями здоровья, инвалидами (детьми-инвалидами) невозможно или затруднено.»;

д) в части 5 слова «с умственной отсталостью» заменить словами «с нарушением интеллекта», слова «со сложными дефектами» заменить словами «с тяжелыми множественными нарушениями развития»;

е) в части 8 слова «с различными формами умственной отсталости» заменить словами «с нарушением интеллекта»;

ж) часть 9 дополнить словами «, инвалидами (детьми-инвалидами)»;

з) часть 10 изложить в следующей редакции:

«10. Обучающимся с ограниченными возможностями здоровья, инвалидам (детям-инвалидам), получающим образование за счет бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан, бесплатно предоставляются специальные учебники, учебные пособия и дидактические материалы, специальные технические средства обучения коллективного и индивидуального пользования, услуги ассистентов (помощников), оказывающих необходимую техническую помощь, переводчиков русского жестового языка (сурдопереводчиков, тифлосурдопереводчиков), а также педагогических работников в соответствии с рекомендациями психолого-медико-

педагогической комиссии, за исключением обучающихся за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета.»;

и) в части 12 третье предложение изложить в следующей редакции: «Основанием для организации обучения на дому являются обращение в письменной форме родителей (законных представителей) и медицинское заключение, выданное медицинской организацией в порядке, установленном федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере здравоохранения, о наличии у ребенка заболевания, включенного в перечень заболеваний, наличие которых дает право на обучение по основным общеобразовательным программам на дому, утвержденный федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере здравоохранения.», дополнить предложением следующего содержания: «Основанием для организации обучения в медицинской организации являются обращение в письменной форме родителей (законных представителей) и справка, выданная медицинской организацией в порядке, установленном федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере здравоохранения, подтверждающая факт госпитализации ребенка в медицинскую организацию, оказывающую специализированную, в том числе высокотехнологичную, медицинскую помощь.»;

3) часть 2 статьи 18 после слов «обучающимися с ограниченными возможностями здоровья,» дополнить словами «инвалидами (детьми-инвалидами),».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 марта 2025 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
05 марта 2025 года
№ 15-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 өлешендә «төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда педагог хезмәткәрләр әзерли торган документларның әлеге федераль орган тарафыннан раслана торган исемлегенә өстәп, мондый документларның өстәмә исемлеген расларга хокуклы» сүзләрен «Федераль законның 47 статьясындагы $6^1$ өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән документларның әлеге федераль орган тарафыннан раслана торган исемлегенә өстәп, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда педагог хезмәткәрләр әзерли торган документларның өстәмә исемлеген расларга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 статьяда:

а) исемдә «белем алучыларның» сүзләреннән соң «, инвалидларның (инвалид балаларның)» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларны, инвалидларны (инвалид балаларны) укытуны һәм тәрбияләүне оештыру шартлары психологик-медик-педагогик комиссия тәкъдимнәре, ә инвалидлар (инвалид

балалар) өчен шулай ук инвалидны (инвалид баланы) индивидуаль реабилитацияләү һәм абилитацияләү программасы нигезендә билгеләнә.»;

в) 2 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга, инвалидларга (инвалид балаларга) гомуми белем бирү яраклаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда психологик-медик-педагогик комиссия тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.»;

г) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Законда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның, инвалидларның (инвалид балаларның) белем алуы өчен махсус шартлар дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) белем бирү эчтәлеген яраклаштыруны тәэмин итә торган һәм мондый укучыларның психофизик үсеше үзенчәлекләрен һәм сәламәтлеге торышын исәпкә ала торган яраклаштырылган белем бирү программаларын, укыту һәм тәрбияләү ысулларын һәм чараларын куллануны үз эченә алган белем бирү, тәрбияләү һәм үстерү шартлары;

2) төркемләп һәм индивидуаль рәвештә коррекция дәресләре үткәрү;

3) махсус дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары һәм дидактик материаллар, күмәк һәм индивидуаль кулланыла торган махсус техник укыту чаралары белән тәэмин итү;

4) психологик-медик-педагогик комиссия тәкъдимнәре нигезендә кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче), рус ишарәләр теленнән тәрҗемәче (сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче), шулай ук педагог хезмәткәрләр хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү;

5) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар бинасына һәм бүлмәсенә кереп йөрү мөмкинлеген тәэмин итү;

6) сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның, инвалидларның (инвалид балаларның) уку-укыту программаларын үзләштерүе алардан башка мөмкин булмаган яисә кыенлаша торган бүтән шартлар.»;

д) 5 өлештә «акылга зәгыйфь» сүзләрен «интеллекты бозылган» сүзләренә алмаштырырга, «катлаулы дефектлары булган» сүзләрен «үсешендә күптөрле авыр җитешсезлекләр булган» сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 өлештә «акылга зәгыйфьлекнең төрле рәвешләрендә» сүзләрен «интеллектлары бозылган» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 өлештә «белем алучыларның» сүзләреннән соң «, инвалидларның (инвалид балаларның)» сүзләрен өстәргә;

з) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре исәбеннән белем алучы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга, инвалидларга (инвалид балаларга), федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән белем алучылар моңа керми, түләүсез махсус дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары һәм дидактик материаллар, күмәк һәм индивидуаль кулланыла торган махсус техник укыту чаралары бирелә, психологик-медик-педагогик комиссия тәкъдимнәре нигезендә кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче), рус ишарәләр

теленнән тәрҗемәче (сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче), шулай ук педагог хезмәткәрләр хезмәте күрсәтелә.»;

и) 12 өлештә өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Белем бирүне өйдә оештыру өчен нигез булып ата-ананың (законлы вәкилләрнең) язма рәвештәге мөрәҗәгате һәм балада сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган төп гомуми белем бирү программалары буенча өйдә белем алуга хокук бирә торган авырулар исемлегенә кертелгән авыруның булуы турында сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә медицина оешмасы тарафыннан бирелгән медицина бәяләмәсе тора.», түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Белем бирүне медицина оешмасында оештыру өчен нигез булып ата-ананың (законлы вәкилләрнең) язма рәвештәге мөрәҗәгате һәм баланы махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмасына госпитализацияләү фактын раслый торган сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә медицина оешмасы тарафыннан бирелгән белешмә тора.»;

3) 18 статьяның 2 өлешендә «сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның» сүзләреннән соң «, инвалидларның (инвалид балаларның)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 05 март
№ 15-ТРЗ